КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 13 март г.Казань № 203

2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 13 март, 203 нче
карары белән расланды

2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 328 номерлы карары белән расланган «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасының 15 нче кушымтасында бирелгән Пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге челтәрен төзү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – Үзәк, субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

2. Бюджет акчасын алучы буларак 2026 елга субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган).

3. Субсидия Вәкаләтле орган тарафыннан, сайлап алуда катнашучының сайлап

алу критериена туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявка) рәсми сорау алу юлы белән үткәрелә торган субсидия алучыларны сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә.

Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр:

заявка – сайлап алуда катнашу өчен әлеге Тәртипнең таләпләре нигезендә рәсмиләштереп тапшырыла торган документлар;

субсидия алучы – сайлап алуда җиңүче дип танылган һәм аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән сайлап алуда катнашучы;

комиссия – сайлап алуда катнашу өчен бирелгән заявкаларны карап тикшерү максатларында формалаштырылган Вәкаләтле органның киңәшмә органы;

фәнни-җитештерү үзәге – «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәдә булган, пилотсыз авиация системаларын әзерләү, сынау, сертификацияләү, җитештерү һәм базарга чыгару чараларын гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган, кимендә 2 500 кв.метр гомуми мәйданлы биналар, төзелмәләр, корылмалар белән тәэмин ителгән технологик инфраструктура;

килешү – Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү.

5. Субсидия турында мәгълүмат субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Вәкаләтле орган һәм комиссиянең сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештәге документларны файдаланып гамәлгә ашырыла.

7. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

8. Субсидия бирү ысулы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

9. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә пилотсыз авиация системаларын һәм (яисә) аларның компонентларын һәм комплектлау әйберләрен эшләүдә, сынауда яисә җитештерүдә турыдан-туры катнашучы төп чара булган җиһаз (алга таба – җиһаз) сатып алу чыгымнары, аны китереп бирү һәм җиһазга карата эшләтеп җибәрү эшләрен башкару чыгымнары керә.

10. Сайлап алу критерие – сайлап алуда катнашучының Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан бирелгән пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусы булу.

11. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3,$$

монда:

$З_1$ – җиһаз сатып алу чыгымнары;

$З_2$ – җиһазны китереп бирү чыгымнары;

$З_3$ – эшләтеп җибәрү эшләрен башкару чыгымнары.

$З_1$, $З_2$, $З_3$ чыгымнар күләме әлеге Тәртипнең 25 пунктындагы алтынчы, җиденче абзацлары нигезендә бирелгән чыгымнар сметасы һәм документлар нигезендә билгеләнә һәм бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүчеләр бәяләре турында, бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар күләменнән артып китә алмый.

12. Субсидия бирү «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

13. Субсидия бирү нәтиҗәсе – әлеге Тәртипнең 25 пунктындагы алтынчы абзацы нигезендә бирелгән чыгымнар сметасында күрсәтелгән исемлек буенча һәм санда җиһаз сатып алу. Субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләре килешүдә билгеләнә.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә 2026 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча ирешелергә тиеш.

## II. Сайлап алуда катнашучыга карата таләпләр

14. Сайлап алуда катнашучы субсидия бирүгә заявка (алга таба – заявка) тапшыру датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары булмый, яисә бурычы Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан

Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, сайлап алуда катнашучыга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаган;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый.

15. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын файдаланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыру өчен техник мөмкинлек булмаган очракта, әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә сайлап алуда катнашучының туры килүен раслау сайлап алуда катнашучы тарафыннан, «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутырып, әлеге таләпләргә туры килү турында электрон рәвештә тамгалар куюю юлы белән гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органның ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта, Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә сайлап алуда катнашучының туры килүен раслый торган документлар тапшыруны таләп итәргә хокуксыз (сайлап алуда катнашучы әлеге документларны һәм мәгълүматны Вәкаләтле органга үз инициативасы белән тапшырырга әзер булган очрактан тыш).

## III. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү булдыру һәм урнаштыру тәртибе

16. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм бердәм порталда заявкалар бирә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла. Моннан тыш, сайлап алуны үткәрү турында белдерү хакында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://mpt.tatarstan.ru/) (алга таба – Вәкаләтле органның рәсми сайты) урнаштырыла.

17. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 13 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

заявкалар бирү тәртибе һәм заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсдия бүлү кагыйдәләре, сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган субсидиянең максималь һәм минималь күләме, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан килешүгә кул куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән тыелып калган (калганнар) дип тану шартлары;

бердәм порталда сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен (сайлап алуга йомгаклар ясау турында документны) урнаштыру сроклары, алар сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14нче календарь көннән дә соңрак була алмый.

18. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турында белдерү формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән алып заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

заявкалар кабул итә башлау датасы җиткәннән соң сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә әлеге Тәртипнең 29 пунктындагы икенче абзацы нигезендә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

## IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

19. Вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда, шулай ук Вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару очрагы – әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет

йөкләмәләре лимитларын кире алу.

20. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда, шулай ук Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла һәм сайлап алуны үткәрмәү сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

21. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат бирә.

22. Сайлап алу бердәм порталда, шулай ук Вәкаләтле органның рәсми сайтында аны гамәлдән чыгару турында беледерү урнаштырылган көннән алып гамәлән чыгарылган дип санала.

## V. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкаларны формалаштыру һәм бирү тәртибе

23. Сайлап алуда катнашучы «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру һәм әлеге Тәртиптә тапшырылуы каралган документларның (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларның) электрон күчермәләрен «Электрон бюджет» системасына кертә юлы белән электрон рәвештә заявка формалаштыра һәм аны сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда тапшыра.

24. Бирелә торган заявкага сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелырга тиеш.

25. Сайлап алуда катнашу максатларында сайлап алуда катнашучы заявкага түбәндәге электрон рәвештәге документларны кертә:

әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан имзаланган субсидия бирүгә заявка;

сайлап алуда катнашучының билгеләнгән тәртиптә расланган уставы;

заявка бирелә торган датага кадәр 10 көненнән дә иртәрәк бирелмәгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның 1 нче көненә карата салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча, җиһазның исемен, санын һәм кыйммәтен күрсәтеп, чыгымнар сметасы;

заявка бирү датасына кадәр өч айдан да иртәрәк алынмаган, җиһазның белдерелгән кыйммәтенең нигезле булуын, аны китереп бирүне һәм эшләтеп җибәрү

эшләрен башкаруны раслый торган документлар (коммерция тәкъдимнәре, счетлар һәм башка документлар);

Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сайлап алуда катнашучыга Үзәк статусын бирүне раслый торган боерыгы;

Кагыйдәләргә 1 нче кушымтада каралган исемлек нигезендә төзелә торган Үзәкнең функциональ һәм җитештерү специализациясе турында белешмәләр;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан имзаланган субсидия бирү нәтиҗәсенең тәкъдим ителә торган күрсәткече турында белешмә кәгазе;

Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыру өчен сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан (сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең электрон цифрлы имзасы белән) имзаланган һәм сайлап алуда катнашучының мөһере (булганда) сугылган сайлап алуда катнашучы ризалыгы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, субсидия бирүгә бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

26. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре киң таралган, һәркем мәгълүматны карый алган программа тәэминаты чаралары ярдәмендә документны тулысынча карау мөмкинлеге тәэмин итә торган ачык форматта булырга тиеш һәм алар шифрланмаган яисә аларның эчтәлеге белән махсус программа яки технологик чаралардан башка танышып булмый торган чаралар белән сакланмаган булырга тиеш.

27. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

28. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирелү датасы итеп сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкага, «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, имза куелган көн санала.

29. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда, сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 23 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

30. Сайлап алуда катнашкан һәр кеше, бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән алып заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында иң күбе биш рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатма булдыру юлы белән, «Электрон бюджет» системасында аңлатмалар бирүгә рәсми сорау кергән көннән

алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әмма заявкалар бирү төгәлләнә торган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә формалаштырыла торган аңлатманы файдалану мөмкинлеге сайлап алуда катнашкан һәр затка бирелә.

## VI. Заявкаларны карап тикшерү, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

31. Сайлап алуны үткәрү максатларында Вәкаләтле орган комиссия булдыру турында карар кабул итә, ул Вәкаләтле органның боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Комиссия булдыру турында боерыкта түбәндәгеләр булырга тиеш:

комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссиянең шәхси составы турында мәгълүмат;

комиссия вәкаләтләре турында мәгълүмат, аларга түбәндәгеләр керә:

заявкаларны карау;

сайлап алуны үткәрү барышында булдырыла торган беркетмәләргә имза кую.

32. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карары комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән раслана. Әгәр карар кабул иткәндә «хуплап» һәм «каршы» тавышлары саны тигез булса, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч була. Комиссия рәисе булмаганда, комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

33. Заявкаларны карап тикшерү комиссия тарафыннан «Электрон бюджет» системасында заявкаларны карап тикшерү өчен Вәкаләтле органга һәм комиссиягә файдалану мөмкинлеге бирелгән көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органга һәм комиссиягә «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

«Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр дата билгеләнергә мөмкин, әлеге дата җиткәннән соң Вәкаләтле органга һәм комиссиягә бирелгән заявкаларны карау өчен «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге бирелә.

34. Комиссия, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны ачу беркетмәсенә имза куя, әлеге беркетмәдә сайлап алуда катнашу өчен кергән заявкалар турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

юридик затның адресы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратыла торган субсидия күләме.

35. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

36. Әгәр заявка сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, заявка дөрес дип танылa.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә заявканың туры килүе-килмәве хакында карарлар комиссия тарафыннан сайлап алуда катнашучы заявка белән бергә биргән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләре алынган көннәрдә кабул ителә.

37. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

а) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) әлеге Тәртипнең 25 пунктында билгеләнгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

в) тапшырылган документлар һәм (яисә) заявкалар сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

г) әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында заявка составында бирелгән документлардагы мәгълүмат дөрес булмау;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкалар аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелү.

38. Сайлап алу түбәндәге очракларда үткәрелмәгән дип танылa:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

39. Заявканы тулы, һәрьяклап һәм объектив карау максатларында үзләре тапшырган документлар һәм мәгълүмат буенча аңлатмалар алу өчен сайлап алуда катнашучыдан мәгълүмат һәм документлар алырга кирәк булган очракта, Вәкаләтле орган, «Электрон бюджет» системасын файдаланып, документларга һәм мәгълүматка карата сайлап алуда катнашучыдан аңлатма соратып ала, кирәк булса, сайлап алуда катнашучы барлык затларга бертигез дәрәҗәдә җибәрелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауда Вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучы тарафыннан документларга һәм мәгълүматка карата аңлатма бирү срогын билгели, әлеге срок тиешле рәсми сорау урнаштырылган көннән соң килә торган көннән алып кимендә ике эш көнен тәшкил итәргә тиеш.

Сайлап алуда катнашучы, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән сроклар эчендә әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә соратыла торган мәгълүматны һәм документларны булдыра һәм «Электрон бюджет» системасына кертә.

Әгәр сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән

рәсми сорауга җавап итеп соратыла торган документларны һәм мәгълүматны, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән срокта тапшырмаган булса, бу турыда мәгълүмат әлеге Тәртипнең 42 пунктында каралган сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә кертелә.

40. Заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дөрес дип танылган заявкаларны рангларга бүлү комиссия тарафыннан заявкалар керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

41. Сайлап алуда җиңүчеләр дип комиссия тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән, бүленә торган субсидия күләме чикләрендә кергән заявкаларны рангларга бүлү нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучылар таныла.

Рейтингта беренче тәртип саны бирелгән сайлап алуда катнашучыга аның тарафыннан заявкада күрсәтелгән күләмнең күрсәткеченә тигез һәм әлеге Тәртипнең 11, 12 пунктлары таләпләре нигезендә исәпләнгән субсидия күләме бирелә.

Әгәр сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия беренче тәртип саны бирелгән заявкада күрсәтелгән субсидия күләменнән артыграк булса, субсидиянең калган күләме рейтингка кертелгән калган сайлап алуда катнашучылар арасында бүленә.

Рейтингка кертелгән сайлап алуда катнашучы һәр чираттагы затка аның тарафыннан заявкада күрсәтелгән күләмгә тигез булган һәм әлеге Тәртипнең 11, 12 пунктлары таләпләре нигезендә исәпләнгән күләмдә субсидия бирелә.

Әгәр сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкада күрсәтелгән һәм әлеге Тәртипнең 11, 12 пунктлары таләпләре нигезендә исәпләнгән субсидия күләме субсидиянең бүленмәгән күләменнән артыграк булса, мондый сайлап алуда катнашучыга, аның ризалыгы белән, сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкада күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен үзгәртмичә, субсидиянең барлык бүленми калган күләме бирелә.

42. Сайлап алуны тәгалләү һәм җиңүчеләрне билгеләү максатларында түбәндәге мәгълүматлар бирелгән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе булдырыла:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа (аларга) бирелә торган субсидия күләме.

43. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе бердәм порталда сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре нигезендә автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

44. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, мондый үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Тәртипнең 43 пунктында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

45. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе басылып чыкканнан соң биш эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә, ул Вәкаләтле орган җитәкчесе (яки ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан раслана.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 25 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

б) субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

## VII. Килешүләр төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

46. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) белән килешү сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) билгеләнгәннән соң тугызынчы эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Вәкаләтле органга элегрәк җиткерелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт кертелә.

Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы белән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

47. Юридик зат булган субсидия алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

48. Вәкаләтле орган, сайлап алуда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта яисә

сайлап алуда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат бирелгән очракта, сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тартырга мөмкин.

49. Субсидия алучы, әгәр әлеге Тәртиптә, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы зат тарафыннан килешүгә имза кую тәэмин ителмәгән очракта, килешү төзүдән баш тарткан дип танылa.

50. Вәкаләтле орган субсидия алучыларга субсидия күчерүне субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучыларга Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә (әгәр Россия Федерациясе бюджет законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса) ачылган счетларга заявка составында күрсәтелгән реквизитлар буенча күчерә.

Субсидия алучыга, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

Килешүгә субсидия алучылар өчен чит ил дәүләтләреннән чыккан (шул исәптән эшләр башкарганда, хезмәтләр күрсәткәндә кайтартыла торган) товарларны, шулай ук чит ил гражданнары, чит ил юридик затлары тарафыннан башкарыла торган эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне сатып алуны чикләү һәм (яки) тыю турында шарт кертелә. Әлеге шартларны билгеләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

## VIII. Хисаплылык бирү, субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру тәртибе һәм аларны бозган өчен җаваплылык

51. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 10нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча төзелгән финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган килешүдә субсидия алучы тарафынннна өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

52. Вәкаләтле орган әлеге хисап тапшырылган көннән алып 15 эш көненнән артмаган срокта субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисапны тикшерә.

Субсидия алучы бирелә торган мәгълүматларның дөрес булмавы һәм субсидияне максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

53. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

54. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

55. Бирелгән субсидия акчасы субсидия алучы тарафыннан Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта;

субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 13 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта.

56. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 55 пунктында күрсәтелгән субсидия акчасын кире кайтару срогы бозылган очракта, Вәкаләтле орган әлеге срок чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

57. 2026 елда субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, 2027 елның 1 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Вәкаләтле органга мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат субсидия алучыдан алынган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Субсидия алучының хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗы булу турында карар булмаган очракта, субсидия алучы әлеге акчаны хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга тиеш.

Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнелә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры

_____________________________ ка (га)

_____________________________ тан (нан)

(җитәкченең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында
заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2026 ел, __________, ______ нчы карары белән расланган 2026 елда пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә төзелә торган сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү

үзәге статусына ия оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә ______________________________________________________
(саннар һәм сүзләр белән)
сум күләмендә субсидия бирүегезне үтенәм.

Түбәндәге мәгълүматларны бирәм:

| Т/с | Мәгълүматлар исеме | Сайлап алуда катнашучы мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Муниципаль берәмлекләр территорияләренең гомумроссия классификаторы | |
| 2. | Төп дәүләт теркәү номеры | |
| 3. | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 4. | Салым органында исәпкә куелу сәбәбе датасы һәм коды | |
| 5. | Сайлап алуда катнашучы оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге | |
| 6. | Сайлап алуда катнашучының урнашу урыны | |
| 7. | Сайлап алу катнашучының факттагы адресы | |
| 8. | Элемтәгә керү өчен телефон номеры, юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен почта адресы һәм электрон почта адресы | |
| 9. | Сайлап алуда катнашучының җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) | |
| 10. | Субсидия бирү турында килешүгә имза куярга вәкаләтле зат турында мәгълүмат | |
| 11. | Җаваплы башкаручы турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы, элемтәгә керү реквизитлары) | |
| 12. | Банк реквизитлары, шул исәптән исәп-хисап счеты, корреспондент счеты, банк идентификация коды | |

Кушымталар: 1.
2.

Сайлап алуда катнашучының җитәкчесе ____________________ / _____________ / ______________________
(вазыйфасы) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20 __ ел, «__» ______________

М.У. (булганда)

____________________________________